ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 ноября 2025 г.

№ 8986

2026 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең туризм-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең туризм-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 27 мартындагы 1540 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. 2026 елга расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең туризм-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү

программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны 1 нче кушымтада каралганча;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең өстәмә белем бирү оешмаларында инклюзив белем бирүне оештыру юлы белән сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле, инвалидлыгы булган укучылар өчен өстәмә гомумүстерешле программаларны тормышка ашыруга норматив чыгымнарны 2 нче кушымтада каралганча;

3) туризм-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарга төзәтмә кертү коэффициентын 0,9 күләмендә.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарына туры китереп тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 1 ноябрендәге
8986 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
туризм-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль дислокациясе | Норматив чыгымнар, елына бер укучыга сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетика | шәһәр җирлеге | 9 170 | 16 555 | 19 766 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 9 070 | 16 455 | 19 666 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 9 570 | 16 955 | 20 166 |
| Туризм-туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 9 170 | 16 555 | 19 766 |
| Экология-биология | шәһәр җирлеге | 9 170 | 16 555 | 19 766 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 9 170 | 16 555 | 19 766 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җирлеге | 8 970 | 16 355 | 19 566 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җирлеге | 9 170 | 16 555 | 19 766 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2025 елның 1 ноябрендәге
8986 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең өстәмә белем бирү оешмаларында инклюзив белем бирүне оештыру юлы белән сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле, инвалид булган укучылар өчен өстәмә гомумүстерешле программаларны тормышка ашыруга норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль дислокациясе | Норматив чыгымнар, елга сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | терәк-хәрәкәт аппараты бозылган, психик үсеше тоткарланган, аутистик спектр тайпылышлары һәм үсешендә күп төрле тайпылышлар булган бер укучыга | | | ишетү сәләте начар булган бер укучыга: чукраклар, начар ишетүчеләр, соңрак чукракланган балалар | | |
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетика | шәһәр җирлеге | 18746 | 30778 | 33989 | 13493 | 23032 | 26243 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 18646 | 30678 | 33889 | 13393 | 22932 | 26143 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 19146 | 31178 | 34389 | 13893 | 23432 | 26643 |
| Туризм-туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 18746 | 30778 | 33989 | 13493 | 23032 | 26243 |
| Экология-биология | шәһәр җирлеге | 18746 | 30778 | 33989 | 13493 | 23032 | 26243 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 18746 | 30778 | 33989 | 13493 | 23032 | 26243 |
| Социаль-педагогик һәм икътисадый | шәһәр җирлеге | 18546 | 30578 | 33789 | 13293 | 22832 | 26043 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җирлеге | 18746 | 30778 | 33989 | 13493 | 23032 | 26243 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева